| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ**<br>**КОМИТЕТ ЯНУРУСОВСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО**<br>**ПОСЕЛЕНИЯСАРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **Татарстан Республикасы САРМАН**<br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННЫҢ ЯНУРЫС**<br>**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br><br>**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**423370, Республика Татарстан , Сармановский район,**
**с.Янурусово, ул.Ленина 43 а, тел.4-10-19**

**ИНН 1636005486 КПП 163601001 Р/С 40204810500000570023 БИК 049205001**
**ОГРН 1061687002574**

# РЕШЕНИЕ

28.09.2016г. № 17

Янурыс авылы

Референдум уздыру турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясының 1 пункты, 11 статья Янурыс авыл җирлеге уставын, Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле референдум үткәрүне түбәндәге мәсьәлә буенча алып барырга: «2017 елда Янурыс авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы?:

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

- - җирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерү, урамнар атамалары һәм сынык номерлары белән күрсәткечләр кую, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тотуны да кертеп):
- - җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту.

- җирлектә баллар һәм яшьләр белән эшли башлагач чарларын оештыру һәм тормышка ашыру: - коммуналь каты калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;

-җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:
- җирлектә яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына иректе керү мөмкинлеген тәэмин итү.

"ӘЙЕ "" ЮК».

2. Әлеге карар информацион стендларда урнаштырып игълан ителергә тиеш.

Янурыс
авыл җирлеге башлыгы А. А. Мөхәммәдиева